**ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422350, штп. Апас, Советская урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 235 от 01.09.2026

**Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма үзгәртеп корылган яки бетерелгән очракта, аттестат һәм (яки) аттестатка кушымта дубликатын бирүче оешманы билгеләү турында.**

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 5 октябрендәге «Төп гомуми һәм урта гомуми белем турында аттестатларны һәм аларның дубликатларын тутыру, исәпкә алу һәм бирү тәртибен раслау турында»гы 546 номерлы боерыгының 28 нче пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р  к ы л а :

1. Гамәлгә куючысы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге булган белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма үзгәртеп корылган очракта, аттестатның дубликаты һәм (яки) аттестатка кушымтаның дубликаты хокукый варис булып торучы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан бирелә дип билгеләргә.

2. Гамәлгә куючысы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге булган белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма үзгәртеп корылган очракта, хокукый варис булып торучы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма түбәндәге бурычларны үз өстенә ала дип билгеләргә:

– чыгарылыш сыйныф укучыларыннан һәм аларның канунлы вәкилләреннән аттестатларның дубликатларын һәм (яки) аттестатка кушымталарның дубликатларын бирү турында гаризалар кабул итү;

- Россия Федерациясенең гамәлдәге кануннары һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 5 октябрендәге «Төп гомуми һәм урта гомуми белем турында аттестатларны һәм аларның дубликатларын тутыру, исәпкә алу һәм бирү тәртибен раслау турында»гы 546 номерлы боерыгы беләән билгеләнгән тәртиптә аттестатларның дубликатларын һәм (яки) аттестатка кушымталарның дубликатларын рәсмиләштерү һәм бирү.

3. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесен, гамәлгә куючысы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль

берәмлеге булган белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма бетерелгән очракта, аттестатның һәм (яки) аттестатка кушымтаның дубликатын бирүче оешма итеп билгеләргә.

4. Гамәлгә куючысы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге булган белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма бетерелгән очракта, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе түбәндәге бурычларны үз өстенә алуын билгеләргә:

– чыгарылыш сыйныф укучыларыннан һәм аларның канунлы вәкилләреннән аттестатларның һәм (яки) аттестатка кушымталарның дубликатларын бирү турында гаризалар кабул итү;

- Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 5 октябрендәге 546 номерлы «Төп гомуми һәм урта гомуми белем турында аттестатларны һәм аларның дубликатларын тутыру, исәпкә алу һәм бирү тәртибен раслау турында»гы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә аттестатларны һәм (яки) аттестатка кушымталарның дубликатларын рәсмиләштерү һәм бирү.

5. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитетының 2026 елның 3 июнендәге 130 номерлы «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма бетерелгән очракта аттестатның һәм (яки) аттестатка кушымтаның дубликатын бирүче оешманы билгеләү турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Җитәкче** **Б.Н. Әхмәтҗанов**